| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кучуковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Көчек авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

12.08.2020 Түбән Көчек авылы № 57-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының «Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм чараларны күчерү тәртибе турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 50-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм чараларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы карары нигезендә, җирлекнең муниципаль норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Советының «Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм чараларны күчерү тәртибе турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 50-3 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 нче кушымтаның 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза алынмаган бүләк җирле үзидарә органы тарафыннан бүләкне җирле үзидарә органы эшчәнлеген

тәэмин итү өчен файдалануның максатка ярашлылыгы турында комиссия бәяләмәсен исәпкә алып кулланыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе

Р.Ә.НУРМӨХӘМӘТОВ